**Питрәч үзәкләштрелгән китапханәләр челтәре**
**Үзәк китапханә**

# Табигатькә сәяхәт экологик КВН

Питрәч 2018 ел

Максат:

1) укучыларның экологик белемнәрен арттыру;
2) әйләнә –тирәнең пычрану, зарарлану сәбәпләрен ачыклау;
3) туган якка мәхәббәт, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.
Кичәнең барышы

Алып баручы: Исәнмесез, кадерле укучылар ! Без бүген "Табигатькә сәяхәт" дип исемләнгән экологик уенга җыелдык.

Табигать – безнең бүгенге байлыгыбыз гына түгел, киләчәгебез дә. Аның байлыгын бездән соңгы килгән буыннарга да калдыру безнең уртак бурычыбыз. Кеше табигатьнең аерылгысыз бер өлеше.

Ул табигатьтән башка бер генә көн дә, бер генә сәгать тә, бер генә минут та яши алмый, аңа су, һава, азык- төлек, җылылык һәм яктылык кирәк. Шуңа күрә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк, шәфкатьле булырга тиеш.

Хәзер сезгә иң беренче командаларга бүленергә туры киләчәк.
Үз командагызның исемен уйларга кирәк булыр. Команда исемегезне язып куярсыз.

**1 нче конкурс. Сорау- җавап дип атала.**
1.Табигатькә кирәкмәгән көнкүреш калдыклары бик күп, ләкин аларны кабат кулланырга мөмкин.Сүз нәрсә турында бара?

- Аны сыер барлыкка китерә. Аз гына булганда, ул бик файдалы. Артык күп булса,начар. Сулыкларга эләксә ул балыкларны, су хайваннарын үтерә. Аны ашлама итеп бакчаларга кертәләр. **(тирес)**

2. Аны кытайлылар уйлап тапкан. Бездә аны агачтан алалар. Ул тиз яна. Бик күп чүп хасил итә. Аңа язалар һәм ясыйлар. **(кәгазь)**

3.Аны комнан ясыйлар.Ул үтә күренмәле. Җиргә төшсә ватыла. Җылытканда камыр төсле матдәгә әйләнә. Урманда ташлап калдырсаң, пожар чыгарга мөмкин. **(пыяла)**
- Һәрвакыт кара төстә. Завод –фабрикалар булган шәһәрдә ул бик күп. Ул бик

зыянлы. Кешеләрдә авыру барлыкка китерә, киемнәрне пычрата. Янганда барлыкка килә. **(корым)**

4. Агачны куактан ничек аерырга. **( агачның кәусәсе бер генә, куакныкы куп).**

**2 нче конкурс. “Дәвам ит”**
1.Чираттагы ярышыбыз “дәвам ит” дип атала. Әйтә башлаган җөмләне сез тәмамлап бетерергә тиеш.

2. Пыяла банкадагы эчемлекләрне сатып алырга тырышыгыз, чөнки ул банкаларны (кабат кулланырга, кибеткә тапшырырга мөмкин).

3. Иске уенчыкларны, китапларны ташлама, алар (кемгәдер кирәк булырга мөмкин)

4.Якын –тирәдә макулатура кабул итә торган пунктның кайда урнашканын бел һәм ( тотылган кәгазьләрне тапшыр)

5.Калай банкаларны ташлаганчы, аларны (ю һәм бөк)

6. Пенопластан файдаланмаска тырыш, чөнки алар
( табигатьтә таркалмыйлар)

**3 нче конкурс. “Кроссворд”**
**Сезгә кроссворд тәкъдим итәбез. “Уткойрык” сүзе килеп чыгарлык итеп, горизонталь шакмакларга кош исемнәре язабыз.**

**4 нче конкурс.“Йөзгә бер”**
**Сезгә экологик темага сораулар бирелә. Кайсы команда тизрәк җавап бирер.**

1. Кем ул эколог?
**Табигать саклаучы**
2.Инфекцияне иң күп таратучы
**Күсе**

3.Автомобильләр һаваны нинди матдә белән пычрата?
**Угар газ**
4.Сез өегезнең нинди материалдан булуын телисез?
**Агач**
5.Дөньядагы иң зур кош?
**(Африка тәвә кошы)**
6.Бездән җылы якка иң соңыннан нинди кошлар очып китә?
**(казлар)**
7.Кайсы кош каты тешли?
**(кошларның теше юк)**
8.Нинди кош ялтыравык әйберләргә кызыга?
**( саескан)**
9.Кайсы кошлар җәен –соры, кышын – ак?
**(поляр ябалак)**
10.Дөньяда иң күп таралган кошлар?
**(чыпчыклар)**
11.Ярканатның йомыркасы нинди төстә?
**(ярканат йомырка салмый)**
12.Кайсы кош баласын бер тапкыр да ашатмый?
**(күке)**

**5 нче конкурс. "Мине таны" уены дип атала**
Ике командага да рәсемнәр бирелә. Шул рәсемдә күрсәткән хайванны кыланып күрсәтергә. Ә икенче команда танып әйтергә тиеш.

**6 нчы конкурс"Агачлар телен иң яхшы белүче" конкурсы.**

1. Язын шаулый, җәен җиләсләндерә, көзен сыйлый, кышын җылыта. Нәрсә ул? **(Урман)**
2. Кышын да, җәен дә бартөсле кием кия. (**Чыршы, нарат)**
3. Нинди агач җилсез дә шаулый? **(Усак)**
4. Иелә, бөгелә,

Ак мамыгы түгелә;

Кара күзе күренә. **(Шомырт)**

**7 нче бәйге «Шаянворд».**

1. - эт чаба дип чабучы бөҗәк (бет)

2. - үзең утырган ботакка чаба торган эш коралы (балта)
3. - эт- эткә, эт- … (койрыкка)
4. - утын төяп бармый торган җир  (урман)
5. - шулпа эчертә торган район (Лаеш)
6. - бору өчен уңайлы булган кеше әгъзасы (колак)
7. - борын чистарту җайланмасы (бармак)

**8 нче конкурс “Моң-зар” конкурсы.**

**1 командага:**

Матурлыгыма сокланып мине күпме кеше өзә. Ә миңа чәчәк атар өчен 10 ел вакыт кирәген уйламыйлар да. Кешеләр миннән йөрәк авыруларын дәвалаучы тамчылар алалар. Элек мине кайда да очратырга мөмкин булса, хәзер мин яклауга мохтаҗ.  **(Энҗе чәчәк )**

Матур түгел икәнлегемне үзем дә беләм. Мине күрсәләр, күпләр читкә тайпыла, таш ыргыта, яки аяклары белән тибеп җибәрәләр. Барысы да матур булмый инде. Ләкин мин кешеләргә зур файда китерәм. Матур тавышларыбыз өчен японнар безне өйдә тоталар**.  (Гөберле бака)**

**2 командага:**

Без елдан-ел азаябыз. Табигать безгә иртә чәчәк ату бурычы куйган. Кеше, кыш буе чәчәккә сусап, юри генә, кулына тотып карау өчен безне өзә, таҗларны тотып карый, ташлый. Ә бит без аңа күпме файда китерә алыр идек. Без бит әле бал кортларына да кирәк. Яз көне аларга азык табу авыр. Ә безнең чәчәкләргә теләп куналар. Кешеләр үзләре бездән дару ясыйлар.  **(Үги ана яфрагы)**

Безнең турында күп легендалар, уйлап табулар сөйлиләр. Без кошларга һәм җәнлекләргә охшамаганбыз. Без караңгылыкны яратабыз. Ләкин без дошманнар түгел, ә кешенең дуслары. Башны аска каратып эленеп торырга яратабыз. Ямьсез булганыбызга без гаепле түгел бит инде.  **(Ярканат)**

**Экологик викторина.**

1) Урманда ташлап калдырылган кәгазь черемичә ничә ел саклана? ( 2-3 ел)

2)Җирдә калдырылган полиэтилен пакет нишли? ( Таркалмый, череми саклана ).

3)Урманда пыяладан янгын ничек чыгарга мөмкин?( Пыяла линза кебек була).

4)Походтан калган чүп-чарны урманда кая куярга? ( Учакта яндыргач, күмеп куярга).

5)Походтан калган буш консерв савытларын нишләтергә?

(Яндырып күмәргә).

6)Гөмбә, җиләк, дару үләннәрен ничек җыялар?( Автомобиль һәм тимер юллардан еракта үскән гөмбәләрне кисеп җыялар, дару үләннәрен кирәкле, файдалы вакытында гына өзәргә ярый).


7)Урманда учакны ничек тергезергә?( Кәсне алып, учак ягарга. Аннан учакны сүндергәч, кәсне яңадан каплап куярга кирәк).

8)Ни өчен урманда чәчәк җыярга ярамый?( Алар арасында бик сирәк очрый торган, Кызыл китапка кертелгәннәре булуы бар)


Йомгаклау.


-Укучылар, бүгенге кичәбез ахырына якынлашып килә. Без табигатьне саклауда һәрберебез үз өлешебезне кертә алабыз. Табигать-ул яшәү чыганагы! Табигать- бездән,без- табигатьтән башка яши алмыйбыз. Әйдәгез, табигатьне саклыйк,хөрмәт итик.

1. Кук кукри, яшен яшьни, нәрсә ява?
2. Бураннан соң бөтен җирдә, нәрсә ята?
3. Кыш көне көчле җил исә, кар ява,бу нәрсә?
4. Кич белән һавада нәрсә бплкый?
5. Кыш көне агачлар нәрсә белән каплана?
6. Зәп-зәңгәр, анда кояш балкый, ай яктырта. Ул нәрсә?
7. Яңгыр ява, кук кукри, нәрсә яши?
8. Җәй көне иртән җиргә нәрсә төшә?



1. Тәрәзәсе юк, ишеге юк, эче тулы халык.
2. Җир астында алтын казык.
3. Йөз кат кием, барысы да төймәсез
4. Алма, дисәң дә алалар, нәрсә соң ул балалар
5. Озын –озын агачлар, агачларда оялар, оярларда  кошчыклар.
6. Җир астында җиз бүкән, ул ни икән
7. Ите симез, мае юк, тиресе калын йоны юк
8. Олысы да, кечесе дә ап-ак эшләпә кия
9. Эче кып- кызыл, тышы ямь – яшел.










7Б


29
29


29
29


7Б


7Б




























7Б



